РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» сентябрь 2021 ел г. Альметьевск № 1335

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасын инновацион үстерү өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен «Менеджер» 23 нче урта мәктәп» хосусый гомуми белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 1090 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тәкъдимнәре нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасын инновацион үстерү өлкәсендә агымдагы эшчәнлекне тәэмин итү өчен «Менеджер» 23 нче урта мәктәп» хосусый гомуми белем бирү учреждениесенә Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 елның 30 июлендәге 1090 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карар исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасын инновацион үстерү өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма субсидияләрен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан бирү тәртибен раслау турында»;

преамбулада «Россия Федерациясе Бюджет кодексы» сүзләреннән соң «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен өстәргә»,»;

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасын инновацион үстерү өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма

Зак. № 305-2000

субсидияләрен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан бирү тәртибен (1 нче кушымта) расларга.»;

карарга 1 нче кушымтада:

1 нче кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф системасын инновацион үстерү өлкәсендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешма субсидияләрен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан бирү тәртибе»;

1 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Әлеге Тәртип муниципаль учреждение булмаган социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмага уставта билгеләнгән агымдагы эшчәнлекне финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү шартларын билгели (алга таба - субсидияләр, Учреждение).»;

1 нче кушымтаның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Финанслау чыганагы - район Башкарма комитетының резерв фонды (алга таба - резерв фонды) булган субсидияләр Учреждениенең коммуналь хезмәтләре өчен түләүгә җибәрелә.»;

1 нче кушымтаның 8 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гаризаны кабул итеп алган һәм теркәгән көннән алып 5 эш көне эчендә районның башкарма комитеты аңа кушымта итеп бирелгән документларны һәм бүлеп бирелгән акчаларның күләме, аларны тоту максатлары яисә район башкарма комитетының структур бүлекчәсе әзерләгән акчаларны бүлеп бирүнең максатчанлыгы турында бәяләмәне карый һәм субсидия бирү турында йә аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.»;

1 нче кушымтаның 10 пунктында «(алга таба - Килешү)» сүзләреннән соң «резерв фондтан субсидияләр рәвешендә акчалар бүлеп бирү турында район башкарма комитеты күрсәтмәсенә кул куйганнан соң» сүзләрен өстәргә.»;

1 нче кушымтаның 14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Хисап аеннан соң килүче айның 10 нчы числосына кадәр тиешле чыгымнарны уздырганнан соң, Учреждение район башкарма комитетына һәм Финанс-бюджет палатасына чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап тапшыра, аларны финанс белән тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Финанс - бюджет палатасы тарафыннан билгеләнгән Килешүнең типовой формасы буенча субсидия булып тора.».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы
вазифаларын башкаручы

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

О.Н. Шабалин